| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2018 Казан ш. № 10-12/кс

"Биектау коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыяте өчен ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында

"Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында" 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында" 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ташлындык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Биектау коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыяте өчен ташландык суны чыгаруга тарифны әлеге карарга кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Ташлындык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Биектау коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыятенә һәркем өчен ачык булырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән дә соңга калмыйча ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
2018 елның 20 июлендәге 10-12/кс
номерлы карарына кушымта

Ташлындык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы "Биектау коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыяте өчен ташландык суны чыгаруга тариф

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ташландык суны чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән алып<br><br>2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Биектау муниципаль районы | |
| 1. | "Биектау коммуналь челтәрләре" акционер җәмгыяте | |
| 1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 42,07 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | 35,65 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге